Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№24 (75)

18 июль 2013 ел

## • Вакыйгалар әзеннән

**14 ИЮЛЬ** көнне Универсиада авылының Халыкара мәгълүмати үзәгендә FISUның **«УНИВЕРСИТЕТ ҺӘМ ОЛИМПИЯ СПОРТЫ: ИКЕ МОДЕЛЬ – БЕР МАКСАТ?»** дип аталган **КОНФЕРЕНЦИЯСЕНЕҢ АЧЫЛЫШЫ УЗДЫ**. Тантаналы чарада FISU җитәкчесе **КЛОД-ЛУИ ГАЛЬЕН**, Татарстан президенты **РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ**, Россиянең спорт министры урынбасары **НАТАЛЬЯ ПАРШИКОВА**, Россия студентлар спорты союзы башлыгы **ОЛЕГ МАТЫЦИН**, Россия Олимпия комитеты генераль сәркатибе **МАРАТ БАРИЕВ** һәм башка рәсми кунаклар катнашты. Конференция программасында КФУ ректоры **ИЛШАТ ГАФУРОВНЫҢ** «Заманча этапта Казан университетында студентлар спортының үсеше һәм тарихи традицияләре» темасына чыгышы тәкъдир ителде.

• • • •

**16 ИЮЛЬ** көнне Мәскәүдә 45нче **ХАЛЫКАРА ХИМИЯ ОЛИМПИАДАСЫНЫҢ** тантаналы **АЧЫЛЫШЫ БУЛДЫ**. Россия командасы составында быел Казан мәктәбе укучысы Михаил Ягофаров та бар иде. Ул ике ел дәвамында Казан университетының физика химиясе кафедрасында химия буенча олимпиадаларга әзерләнергә йөргән. Олимпиада Мәскәү дәүләт университетында 8 көн буе дәвам итәчәк. Җиңүчеләр 23 июль көнне билгеле булачак.

• • • •

**16 ИЮЛЬДӘ КФУ**га эшлекле визит белән Украина Мәгариф министрының беренче урынбасары **ЕВГЕНИЙ СУЛИМА** һәм Украинаның Түбән Новгородтагы генераль консулы **ИГОРЬ МЕЛЬНИЧУК КИЛДЕЛӘР**. Университетыбыз вәкилләре һәм кунаклар Татарстан һәм Украинадагы югары белем бирү өлкәсе буенча тәҗрибә уртаклашты. Шулай ук үзара хезмәттәшлек турында да сөйләшүләр булды.

• • • •

**КФУ**ның **КАБУЛ ИТУ КАМПАНИЯСЕ УЗ ЭШЕН 25 ИЮЛЬГӘ КАДӘР ДӘВАМ ИТӘЧӘК**. Бүгенге көнгә бюджет урыннарга – 36 мең 866, түләүлегә исә 12 мең 674 гариза кабул ителгән. Иң популяр булып Идарә һәм территориаль үсеш институты тора. 30 июльдә укырга кабул ителергә мөмкин булган абитуриентлар исемлеге чыгачак. Шуннан соң 4 августка кадәр документларның оригиналын китереп бирергә кирәк. 5 августта кабул итүчеләрнең беренче дулкыны билгеле булачак.

• • • •

**14-17 АВГУСТ** көннәрендә **АЛАБУГА ИНСТИТУТЫНДА** дүртенче тапкыр **МӘКТӘП УКЫТУЧЫЛАР ФЕСТИВАЛЕ УЗАЧАК.** Быел ул халыкара статус алды. Фестиваль кысаларында лекцияләр, түгәрәк өстәлләр, уеннар, мастер-класслар, тәҗрибә уртаклашулар булачак. Мастер-классларны алып бару өчен, Россия, Германия, Испания, Кытай, Төркия, Украина һәм Сингапурдан алдынгы белгечләр киләчәк.

• • • •

**ЕВРОПА КОМИССИЯСЕ САЙТЫНДА** Erasmus Mundus (Action 2 и Action 3) программасы кысаларында **ПРОЕКТЛАР КОНКУРСЫНЫҢ НӘТИҖӘЛӘРЕ ЯКТЫРТЫЛДЫ**. КФУ co-координатор булган «EU-Russia: Towards Modern and Innovative HigherEducation» (AURORA II) проекты дүрт елга матди ярдәмгә лаек булды. Бу – Казан университеты каткашкан Erasmus Mundusның өченче эре проекты. Анда катнашучыларны сайлау быелның октябрь аенда башланачак. Шул уңайдан уку йортыбызда октябрь-ноябрь айларында проектта катнашуга бәйле рәвештә презентацияләр һәм консультацияләр булачак.

• • • •

Күптән түгел М.В.Ломоносов ис. Нечкә химик технологияләрнең Мәскәү дәүләт университетында Россиядә химия термодинамикасы буенча **XIX ХАЛЫКАРА КОНФЕРЕНЦИЯ БУЛЫП УЗДЫ**. Анда КФУның А.М. Бутлеров ис. Химия институтының физик химия кафедрасы хезмәткәре **ИЛНАЗ РӘКЫЙПОВ** уңышлы чыгыш ясады. Аның докладкы үз секциясендә иң яхшысы дип табылды.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*



Җәмигъ мәчете һәм зур манара



Кече манара һәм ханнар төрбәсе




Ак мәчет

# КФУ ышанычны аклар

**Алинә САДЫЙКОВА**, хәбәрче

16 июль көнне РФ Дәүләт Думасының Федераль җыелыш рәисе, Россия тарих җәмгыяте рәисе Сергей Нарышкинның Казанга визиты кысаларында КФУда РТҖнең Казан бүлеге учредительләре җыелышы узды.

«Әлеге утырышны үткәрү урыны итеп КФУны сайлау юкка түгел,чөнки уку йортыбыз үзенең тарихи йөзен динамик үсеш-үзгәреш заманында да югалтмый», – дип башлап җибәрде утырышны **И.Гафуров**.

Утырыш карары белән Казанда Россия тарих җәмгыятенең төбәк бүлеге булдырылды. Тарих җәмгыяте тарихи мәдәниятне өйрәнү, тарихи үзәкләрне арттыру, дөнья һәм ватан тарихын яктырту һәм популярлаштыру, милли хәтерне саклау өстендә эшли. Аның беренче бүлеге бер ел элек Санкт-Петербург шәһәрендә үз эшчәнлеген башлап җибәрде һәм икенчесе менә безнең шәһәрдә ачылды. «Бүлекне булдыру идеясе белән безгә Казан федераль университетының тарихчылары мөрәҗәгать итте. Минемчә, КФУ тарих җәмгыяте вәкилләрен бергә берләштерә ала торган дөрес һәм яхшы мәйданчыкка әвереләчәк. Бүгенге көндә безнең алда торган тагын бер мәсьәлә – ватан тарихы буенча яңа укыту-методик комплектлар булдыру һәм шуның базасында мәктәп дәреслекләре төзү. Бу өлкәдә дә үзенчәлекле тарихы һәм матур традицияләре булган Татарстанның пилотлы проекты мәктәпләрдә тарих фәнен укыту буенча яңа компетенцияләр булдырырга ярдәм итәчәк» – дип, **Сергей Нарышкин** уку йортыбызга һәм республикабызга зур өметләр баглады.

И.Гафуров әлеге эшчәнлекне алып бару өчен барлык мөмкинлекләр дә бар дип исәпли: «РТҖнең чираттагы бүлеген Казанда булдыру – тарихи тикшеренүләр өчен яңа импульс, ул Россия тарихының бердәм концепциясен формалаштырырга ярдәм итәчәк. Без бу эшкә әзер!» КФУ – традицияләргә бай булган уку йорты, шуңа күрә ул җитәкчелек баглаган ышанычны һичшиксез аклаячак.

Җыелыш барышында С.Нарышкин Минтимер Шәймиевне РТҖнең шәхси әгъзалык таныклыгы белән бүләкләде. Әлеге җәмгыять Советы карары нигезендә, РТҖнең Казандагы бүлек рәисе итеп КФУ галиме **Рамил Хәйретдиновны** билгеләделәр.

**Ахыры 2нче биттә.**

## • Уртак җиңү

# Универсиада тәмам!

XVII Җәйге Универсиада ничек тиз башланган булса, шундый ук югары кәефтә, күтәренке рухта узып та китте.

2013 елгы Җәйге Универсиаданың спорт программасына Универсиада тарихында беренче тапкыр 27 спорт төре кертелде. Аларның 13е мәҗбүри спорт төрләре, шуннан тыш Казан программага рекордлы санда өстәмә спорт төрләре тәкъдим итте. Россия, гомумән, быелгы Универсиадада рекордлар куйды. Беренчедән, Казан бөтен Универсиада башкалалары арасында иң төньяк шәһәр булып тора. Иң масштаблы Җәйге Универсиадада 162 ил арасында 350дән артык медаль комплекты уйнатылды. Медальләр саны буенча, без башка илләрдән килгән командаларны бик күпкә артта калдырып, беренче урынга чыктык.



**Ахыры 2нче биттә.**

● Хезмәттәшлек

# КФУ ышанычны аклар



Башы 1нче биттә.

«Санкт-Петербургтан соң, Казанда мондый үзәк ачылу – бик мөһим чара. Без, беренче чиратта, төбәктә булган проблемаларны хәл итәргә тиеш булачакбыз. Татарстан – күп милләтле республика, шуңа күрә төрле милләткә караган мәсьәләләргә дә игътибар итәчәкбез. Яңа стандартлар нигезендә бердәм тарих китабы чыгару турында да сүз кузгатылды. Бу очракта да, гармонияне саклап, бөтен халыкларның тарихын колчаларга тиеш булачакбыз», – диде Равил әфәнде, фикерләре белән уртаклашып.

Тарих ул археологик эзләнүләр генә түгел, ә зур масштаблы проектлар да әле. Россия тарих җәмгыятенең тагын бер бүлеге Казанда, ә менә нәкъ КФУда ачылу да татар халкы тарихының киләчәгенә йогынты ясамый калмас. КФУ галиме Искәндәр Гыйләҗев та үзәккә зур өметләр баглый: «Бу үзәкнең татар милләтенә файдасы нинди булачагын әлегә әйтү кыен, чөнки күп нәрсә конкрет кешеләрдән, конкрет аралашудан тора. Шәхсән минем аның эшчәнлегенә һәм киләчәгенә өметләрем шактый зур. Моңа кадәр без еш кына Мәскәү галимнәре белән һаман конфликтта, конфронтациядә тора идек. Алар татар тарихына үзләренчә, без үзебезчә бәя бирәбез. Хәзер исә бәхәсле мәсьәләләр туган вакытта, бу җәмгыять ярдәмендә без аларны уртага салып, бер фикергә килү өчен, аралашып, бәлки, ниндидер чаралар, конференцияләр уздырып, барыбызга да ошый торган нәтиҗәгә килә алачакбыз. Конфронтациядән нормаль диалогка юл тотар вакыт җитте. Җәмгыять эшләргә һәм реаль нәтиҗәгә китерергә тиеш. Бу үзәкнең ачылуы нәтиҗәле булыр дип өметләнәбез һәм үзебез дә актив эшләргә әзер». Әйтергә кирәк, Татарстан Россиянең үсешендә шактый зур роль уйный. Атаклы тарихчы, академик Индус Таһиров та бу уңайдан: «СССР таркалганнан соң, Россиянең исән калуында, аның яшәешенә импульс бирелүдә Татарстанның өлеше зур. Шушы кечкенә генә Татарстан Россияне федераль рельсларга бастырды», – диде.

Утырыш ахырында КФУ Россия Фәннәр академиясенең гомум тарих институты, Россия тарихы институты һәм Н.Н.Миклухо-Маклай ис. этнология һәм антропология институты һәм археология институты белән хезмәттәшлек алып барырга сүз куешты һәм килешү кәгазьләренә кул куйды.

● Уртак җиңү

# Универсиада тәмам!

Башы 1нче биттә.

Шулай итеп, безнең исәптә барлыгы 292 медаль, шуларның 155 алтын, 72 көмеш, 62 бакыр булды.

Универсиада студентларның төп спорт ярышы булып тора. Мөһимлеге буенча ул Олимпия уеннарыннан бер дә калышмый. Гадәттә, бу чараның 60 процент катнашучысы Олимпиадада чыгыш ясый. Россия җыелма командасы составында КФУ студентлары да сынатмады. унбиш студентның сигезе җиңүгә ирешә. Тагын бер мәртәбә басым ясап, безнең уку йортында иң талантлы студентлар укый, дип әйтәсе килә.

Кичә Универсиаданың ябылу тантанасы узды. Анда Россия Премьер-министры Дмитрий Медведев һәм башка мәртәбәле кунаклар катнашты. Универсиаданың ябылу чарасы да оригиналь, кабатланмас шоу булуы белән истә калачак.

● Абитуриентлар өчен

# Табигать серләрен белим дисәң

Институт **фәнни үзәкләре, лабораторияләр, практика базалары, метеорологик обсерваториясе** белән дан тота. Студентлар уку белән практиканы берьюлы алып бара. Шулай ук институт «Алабуга» ачык икътисади зона, «Татнефть» ААҖ, Универсиада корылмалары төзүчеләре өчен зур фәнни тикшеренүләр уздыра.



Институтны тәмамлаган белгечләр **тирә-якны саклау, экологик куркынычсызлык, табигый ресурсларны рациональ куллану буенча туган проблемаларны, экологик мониторинг, менеджмент, экосистемаларны сәламәтләндерү** методлары өлкәсендәге мәсьәләләрне профессиональ рәвештә хәл итә.

**Гидрометеорология** юнәлеше буенча белем алып чыккан студентлар башкарган хезмәт һәркем өчен һәркөнне кирәк булачак. Алар атмосфераның составын, төзелешен, физика һәм динамикасын, мәгълүмати һәм космик технологияләр ярдәмендә һава торышын өйрәнә.

**Туризм һәм кунакханә** эше белгечләрен үзләштергән бакалаврлар проектлаштыру институты һәм компанияләрендә, фәнни-тикшеренү оешмаларында, туристлык агентлыкларында, кунакханә, ресторан комплексларында, музей һәм мәгариф учреждениеләрендә уңышка ирешә ала.

**Педагогик белем бирү юнәлешен** тәмамлаган студентлар ике куян койрыгын тотачак. Көндезге бүлектә берьюлы ике белгечлек алырга була: **география+инглиз теле, география+биология, экология+инглиз теле.**

Әгәр сине табигать кызыксындырса, аның белән бәйле проблемалар борчыса, Җир-анабызны саклауга үз өлешеңне кертәсең килсә, Экология һәм география институтына укырга кил. Сине Россиянең генә түгел, чит илләрнең алдынгы уку йортларында стажировка үтү, хезмәт базарында үтемле саналган һөнәрләр, иң матур төбәкләрдә җәйге практика һәм романтик экспедицияләр, әлбәттә инде, онытылмаслык студент еллары көтә.

# Иң нәфис гимнасткалар – безнеке!

**Илмир ВӘЛИЕВ,**
гимнастика үзәге волонтеры

Универсиаданың соңгы көннәрендә гимнастика үзәгендә нәфис гимнастика буенча узган финал ярышларда Россия командасы «алтынга» лаек булды.



Нәфис гимнастика – әле үсеп килә торган спорт төре. Бу спорт төре буенча беренче ярышлар 1941 елда үткәрелә. Шул вакыттан алып, Олимпия уеннары, Универсиада, дөнья чемпионатлары бу спорт төреннән башка узмый. Казанда узган Универсиадада гимнасткаларның лаеклы чыгышы белән тарихта калачак. Аеруча **Анастасия Близнюк, Елена Романченко, Ольга Ильина, Анастасия Назаренко, Анастасия Максимова** и **Ксения Дудкина** составындагы Россия җыелма командасы чыгышы җюри тарафыннан югары бәяләнде. Украина һәм Япония командалары икенче һәм өченче урыннарны бүлеште. Индивидуаль ярышларда да безнекеләр сынатмады. Ярышларда Россиянең нәфис гимнастика федерациясе президенты **Ирина Александровна Винер-Усманова**, ТР премьер-министры **Илдар Халиков**, Россия гимнастикасы, олимпия уеннары чемпионы **Евгения Канаева** да катнашты.



«Универсиада безнең өчен һәрвакыт мөһим вакыйга, башка елгы ярышларда да безнең ил өчен иң көчле гимнасткалар чыгыш ясады. Алар арасында **Ирина Чащина, Алинә Кабаева, Евгения Канаевалар** бар иде. Казандагы Универсиадада да иң булдыклы һәм көчле студент кызлар көч сынашты. Ярышларга без бик тырышып, югары дәрәҗәдә әзерләндек. Нәтиҗәсе дә күз алдыбызда: кызлар пьедесталның иң югары баскычында. Бу һәммәбезнең, иң беренче чиратта, тренерларның, кызларның әзерлек дәрәҗәсен күрсәтә», – диде Россиянең нәфис гимнастика федерациясе президенты.

**Ирина Александровна** Универсиада өчен төзелгән гимнастика үзәге турында да уй-фикерләре белән уртаклашты. «Казандагы кебек Универсиаданы минем беркайда да күргәнем булмады. Миңа бик күп Универсиадаларда катнашырга туры килде, ләкин мондый матурлыкны, әзерлекне беренче күрәм. Универсиада авылында спортчыларга яшәү өчен менә дигән шартлар тудырылган. Ресторанда да җаның ни тели, шуны ашый аласың. Башка спорт объектларының заллары, аеруча гимнастика үзәге искиткеч. Казан Универсиадага Олимпиа уеннарына да лаеклы итеп әзерләнгән. Моның өчен илгә һәм Татарстанга зур рәхмәт әйтәсем килә. Дөнья чемпионатын уздыру өчен, әлегә Казаннан башка шәһәрне күрмим».

Чыннан да, Мәркәзебез берничә ел эчендә танымаслык булды. Махсус Универсиада өчен, 30 спорт корылмасы төзелде. Бу, сәламәт яшәү рәвешен алып бару өчен, казанлыларга менә дигән мөмкинлек. Юллар киңәйтелде, бөкеләр кимеде, урамнар шаучәчәккә күмелде. Бер сүз белән әйткәндә, Казан әкияти шәһәргә әйләнде. XXVII Җәйге Универсиада тарих битләренә мәңгелеккә уелып калачак.

● Рәсми универсиада

15 июль көнне Тышкы элемтәләр буенча проректор Линар Латыйпов Халыкара мәгълүмати үзәктә узган XXVII Бөтендөнья җәйге Универсиаданың спорт делегацияләре утырышында катнашты.

# КФУ белән кызыксыналар

Очрашуда җитмештән артык делегация бар иде. Проректор кунакларга бүгенге Казан университетын тәкъдир итте. Ул аеруча белем бирү мөмкинлекләренә, фәнни казанышларга, халыкара хезмәттәшлеккә һәм уку йорты инфраструктурасына тукталды.

Җитәкче шулай ук КФУда белем алучы чит ил студентлары (бер меңнән артык), алар өчен төзелгән укыту программалары, торак шартлары һәм ашату, спорт ярышларында катнашу һәм студентларның яллары турында сөйләде.

Аерым алганда Фундаменталь медицина һәм биология институты, Физика институты, А.М.Бутлеров ис. Химия институты, Геология һәм кара алтынгаз технологияләре институты, Филология һәм сәнгать институтларының укыту аудиторияләре һәм лаборатория комплекслары белән таныштырды.

Л.Латыйпов чыгышы утырышта катнашучыларда зур кызыксыну уятты. Очрашу тәмамлангач та, аңа бик күп сораулар бирелде.

*Мәгълүмат Тышкы элемтәләр департаментыннан алынды.*

• Тарих эзләреннән

# Иске Татар бистәсе яңара

Иске Татар бистәсе – Казан үзәгендә урнашкан тарихи район. Бистәнең Түбән Кабан күленең уң ярында урнашуы кабатланмас гүзәллек өсти.



Иске Татар бистәсенең барлыкка килүе Явыз Иванның Казанны яулап алуы белән бәйле. Бирегә XVI – XVII гасырларда рус патшасы белән уртак тел тапкан татарлар килеп урнашкан. 1767 елда, Казанга патшабикә Екатерина II килеп киткәннән соң, Иске Татар бистәсе аеруча тиз төзелә башлый. Моңа шулай ук патшабикәнең мәчетләрне һәм җәмәгать биналарын таштан салуны рөхсәт итүе һәм 1773 елда кабул ителгән Диннәрнең тигезлеге хакындагы тарихи указы да уңай йогынты ясый. XIX гасыр ахырына Иске Татар бистәсенең эре ансамбле Мәскәү (элеккеге Киров), Нариман, Мәрҗани (элеккеге Комсомол), Сара Садыкова (Нариман урамының элеккеге көньяк ягы), Г.Камал, Әхтәмов урамнарында пәйда була. Иң кыйммәтле дип саналган өлеше көнчыгыштан көнбатышка таба Сара Садыкова урамына кадәр һәм Мәскәү-Мәрҗани урамнары тирәсендә санала. Шулай ук Г.Камал урамыннан алып, Әхтәмов урамына кадәр төньяктан көньякка таба да тарихи кыйммәткә ия биналар пәйда була. Бистә өчен үзәк булып саналган Тукай урамы (1917 елга кадәр Тихвин һәм Екатерина урамнары) татар сәнәгатьчеләре, эшкуарлар, дин әһелләре йортлары белән дан тота. XVIII гасырда бистәдә татар халкының атаклы кешеләре – интеллигенция вәкилләре, дин эшлеклеләре, сәүдәгәрләр һәм һөнәрчеләр яши. Иске Татар бистәсенең үзәге Юнысов мәйданы була.

Бистәнең йөзен XVIII гасыр ахыры – XIX гасыр башында салынган биналар билгели. Иң кызыклы корылмалар арасында – татар буржуазиясе һәм интеллигенциясе йортлары: Юнысов-Апанаев йорты, Шамил йорты, Шиһабетдин Мәрҗани йорты, Каюм Насыйри йорты һ.б. XIX гасырда бистәдә Шәрыкъ клубы эшләп килә, ул чорда яшәгән шагыйрьләр биредә үз шигырьләрен укый, беренче татар спектакльләре монда уйнала. Бистә территориясендә Мәрҗани, Апанай, Зәңгәр, Галеев, Борнай мәчетләре урнашкан. Иске Татар бистәсенең иң зур мәчете – Печән базары мәчете (хәзерге Нурулла мәчете). Шул тирәләр бистәнең үзәге булган. Бу мәркәз янында кунакханәләр (Болгар, Амур), сәүдә йортлары урнашкан.

Иске Татар бистәсендә шагыйрь Габдулла Тукай, мәгърифәтче Каюм Насыйри музейлары, Галиәскәр Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры урнашкан.

Хәзерге вакытта Казанның тарихи мәркәз истәлекләре урынында яңа йортлар төзелде. Мәрҗани, Каюм Насыйри, Сафьян, Фатих Кәрим һәм Зәйни Солтан урамнары Иске Казанны хәтерләтә. Биш урамда егерме дүрт мәдәни мирас торгызылган.

Иске татар бистәсе Казанга үзенчәлекле, Европа һәм Россия сәяхәтчеләрен таң калдырырлык шәркый төс, колорит биреп тора. Гасырлардан-гасырларга ул үзендә урта гасыр татар-мөселман шәһәренең традицияләрен һәм сурәтен саклап килә. Әлеге урынның уникаль тарихы һәм архитектурасы европалаштыру һәм модернизация дулкыны астында югалып калмый, ә киресенчә, аларны үз мәдәни мирасы ярдәмендә үзгәртеп, бары тик үзенә генә хас мәдәни кыйммәтләр тудыра.

• Татарча Универсиада

# Иле барның теле бар!

**Резеда ӘХМӘТВӘЛИЕВА**,
Гаммәви коммуникация
һәм социаль фәннәр институты

Универсиада авылында спортчылар өчен төрле ял итү, укыту мәйданчыклары арасында лингвистика мәйданчыгы да эшләде. Кайбер спортчылар биредә татар телен өйрәнде.



Телләр мәйданчыгында татар теле дәресләрен алып баручы КФУ доценты Гөлнара Гайнетдинова: «Без Универсиада авылында яшәүче, телләр өйрәнергә теләүче спортчыларга лингвистик мәйданчык оештырдык. Ул КФУ укытучылары инициативасы белән тормышка ашырылды. Анда татар яки рус теле өйрәнергә мөмкин. Ике сәгатьлек дәресләр ул. Бер сәгате – рус телен, икенчесе татар телен өйрәнүгә багышлана. Теләүчеләр бик күп булмады, чөнки спортчыларга актив ял итү кызыграк», – диде. Татарча сүзтезмәләрне биредә Хорватия, Мисыр, Япония, Яңа Гвинея студентлары өйрәнгән. Ул дәресләр 6 июльдән 17 июльгә кадәр көн саен барды.

Темалар арасында спорт, татар ризыклары, гаилә белән бәйлеләре бар. Саннарны да өйрәткәннәр. Кайбер сүзләр туп белән уйнау, тәрҗемә аша өйрәтелгән. Күп кенә спортчылар, гомумән, гадәти дәресне кабул итә алмау сәбәпле, дәрестә уеннар кулланылган. Татар телен өйрәнүче спортчыларга бүләккә исә көнкүрештә кирәкле татар сүзтезмәләре язылган карталар бирелгән. Аларга татарча да, артына төрле телгә тәрҗемәләр дә язылган.

Универсиада авылында аерым фольклор мәйданчыгы да бар. «Татар халык җырлары яңгыраганда, бирегә, кызыксынып, чит ил студентлары керде. Биючеләрнең татар халык киемнәре үзенә бер зәвык белән тегелгән. Аннан соң урыс музыкасын куйгач, нигәдер, аларга ул кызыклы тоелмады, спортчылар чыгып китте», – дип сөйләде Гөлнара Гайнетдинова. Биредә аерым татар инструменталь ансамбле, аерым татарфильм, кинозал да эшләгән, шулай ук татар халкына кагылышлы лекцияләр дә укылган.

*«Азатлык» сайтыннан алынды*

• Аталар сүзе - акылның үзе

# Питрау җитте – җәй бетте!

**Ләйсән ИСХАКОВА,** Гаммәви коммуникация
һәм социаль фәннәр институты

Җәй нәкъ уртасына якынлашкан көннәрдә үзенә генә хас йолаларны, гореф-гадәтләрне саклап яшәүче керәшен халкы Питрау бәйрәмен үткәрә.





Бәйрәмнең тарихы ерак гасырларга барып тоташа. **Питрау** – православие динен тотучыларның Петр һәм Павел исемле апостолларын искә алу көне. Керәшеннәрдә ул җыр-моң, табигать һәм чәчәк бәйрәме санала. Нәкъ менә 12 июль көнне тереклек дөньясында зур үзгәрешләр күзәтелә башлый, кошлар сайраудан туктый. Керәшеннәрдә, бу көнне җыеп киптерелгән файдалы үләннәрнең төнәтмәсен эчсәң, барлык авырулардан да тереләсең, дигән гыйбарә яши. Керәшеннәр Питрау бәйрәмен табигатьне олылау, аңа табыну, биргәннәренә шөкерана итү, аның матурлыгына, иркенлегенә мәдхия җырлау буларак тәкъдир итә. Халыкның алда торган олы һәм җаваплы эше – уңышны урып-җыю алдыннан ял итеп алу бәйрәме дә әле ул.

Шуңа да республикабызның керәшен халкы үзләренең милли бәйрәмнәрен ел саен зурлап үткәрә. Ә үзәкләштерелгән, барлык керәшеннәрнең берләштерелгән күңел ачуы исә, гадәттәгечә, быел да ундүртенче тапкыр Мамадыш районының Җөри авылы биләмәсендә узды. Биредә уздырыла торган Питрау күптән республика күләмендәге керәшен Сабан туена әверелде инде. Җөри авылы янындагы Тырлау аланы – табигатьнең гаҗәеп матур бер урыны. Бу – таулы-калкулы яклар. Иң югары нокталарның берсенә «Питрау 2013» дип язылган. Шуңа да бирегә килгәндә, һич кенә дә адашырга мөмкин түгел.

Быелгы Питрау да югары дәрәҗәдә оештырылды. Башка еллардагыдан аермалы буларак, быел бәйрәм Мәдәни Универсиада программасына кертелгән иде. Универсиадага бәйле рәвештә, чара шимб ә көнне түгел, ә җомга үткәрелде. Питрауны халык кичке Сабантуй буларак кабул итәргәияләшкән инде. Бәйрәм тантаналы рәвештә 18.00 сәгатьтә ачылды. Питрау кунаклары керәшен йорты ишегалдында сый-хөрмәт татып карый алды. Теләүчеләргә табикмәк, елгыр, коймаклар ашау, кәрҗин үрүче осталарның эшен күзәтү мөмкинлеге бирелде. Үзәк мәйданда урын алучылар керәшеннәрнең җыр һәм биюгә төреп, үзләренең бай мәдәнияте турында сөйләүләрен ишетә алды. Халыклар дуслыгын данлап, үз тирәсенә 50 меңләп кеше туплаган Питрау фестивалендә Россиянең керәшеннәр күпләп яши торган төбәкләреннән килгән фольклор ансамбльләре, эстрада җырчылары чыгыш ясады.


Җөри халкы инде башка авылларда югалган халык уеннары, күңел ачу чараларын саклап кала алган авыллардан санала. Кул белән балык тоту, суда оештырылган башка уеннар керәшен халкы өчен генә түгел, башкаларга да бик кызыклы булды. Бәйрәмнең төп бизәге ул, әлбәттә, көрәш. Биредә Татарстаннан һәм якын тирәдәге башка төбәкләрдән иң көчле, гайрәтле көрәшчеләр бил алышты. Бәйрәм программасында ат чабышлары, халык уеннары, театральләштерелгән тамаша, төрле көч һәм җитезлекне сыный торган уеннар, янган учак тирәсендә керәшен йолаларын башкару каралган иде. «Димчи Горпи почмагы» мәйданында исә егет-кызлар үзара таныша, дуслаша алды. Яшьләр өчен әле менә дигән дискотека да оештырылды. Бары тик Питрау бәйрәмендә генә кызлар кыр чәчәкләреннән җыелган букет конкурсында катнашып, «Керәшен чибәре» титулына ия булырга мөмкин. Быел бәйрәмнең төп чибәре титулы өчен 12 кыз көч сынашты. Җиңүче итеп, Тукай районыннан 20 яшьлек Елена Чулакова танылды.

Керәшен фестивале төнге сәгать икедә бәйрәм салюты белән тәмамланды.

• Универсиада-2013

Универсиаданың нәтиҗәләре сөендерерлек: Россиягә медальләр саны ягыннан тиңнәр юк. КФУ студентлары да илебезнең җыелма командасы җиңүенә үзеннән зур өлеш кертте. Җиңүгә таба юл бормалы һәм урау була. Шул юлларны ничек узулары һәм уңыш сере хакында спортчы студентларның үзләреннән белештек. Яна, Радэль һәм Тоня – КФУның Физик тәрбия һәм терниәкләндерү медицинасы институты студентлары.

# Җиңүгә юл



**Ләйсән ИСХАКОВА,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты



**АНТОНИНА САВЕЛЬЕВА**, Өстәл теннисы буенча Универсиадада ике бронза медаль иясе, Россия чемпионатының көмеш призеры, студентлар арасында Россия һәм Европа чемпионаты җиңүчесе: «Физкультура дәресләрендә өстәл теннисын карарга сыйныф белән бергәләп йөри идек. Ул чакта миңа нибары 6 яшь иде. Беркадәр вакыттан соң, тренер мине сайлап алды һәм мин махсус мәктәпкә йөри башладым. Теннис белән беррәттән, баскетболга йөрдем. Әмма өстәл теннисын сайладым, чөнки ул – травмалар алу ягыннан куркынычсызрак спорт төре. Быелгы Универсиада минем өчен әле беренчесе генә. Ярышлар, иң беренче чиратта, гаҗәеп авыр матчлар һәм Россиягә 2 бронза медаль китергән җиңүләрем белән истә калды. Казанның күзгә күренеп үзгәрүе һәм әзерлекнең югары дәрәҗәдә булуы да сокландырды».



**РАДЭЛЬ КАШЕФРАЗОВ**, Йөгерү буенча юниорлар арасында Европаның көмеш призеры, Европа команда чемпионатының көмеш призеры: «Әлеге спорт төре белән барлыгы 5 елга якын, профессиональ рәвештә 3 ел шөгыльләнәм. Ни өчен нәкъ менә йөгерүне сайлавымны төгәл генә әйтә алмыйм. Кирәкле вакытта тиешле урында булганмын, күрәсең. Шуннан башланды инде... Бу минем беренче Универсиадам. Ярышларны уздыру югары дәрәҗәдә оештырылган. Универсиада авылында тормыш гөрли. Бер урында шулкадәр күп студент җыелсын әле! Шулай да иң тирән кичерешләр җиңү пьедесталына менү белән бәйле».



**ЯНА МАРТЫНОВА**, Йөзү буенча Универсиада 2013 алтын һәм бакыр медаль иясе, 32 тапкыр Россия чемпионы, Дөнья чемпионатының көмеш призеры, Европа чемпионатының бакыр призеры, Дөнья кубогы этаплары җиңүчесе, Россия рекордсмены.

«Йөзү белән 4-5 яшьтә шөгыльләнә башладым. Төп сәбәбе: өйдән бассейнга эләгү өчен, юл аша гына чыгарга кирәк, өстәвенә апам да йөзүгә йөри иде. Шуңа мине дә бу спорт төренә биргәннәр. Казан Универсиадасы – минем икенче Универсиада. Беренчесе 2007 елда Таиланд башкаласы Бангкокта булды. Үзебездәге Универсиада бик шәп, чит илдән килүчеләр шәһәребезне һәм спорт обьектларын мактый, медальләр дә гаҗәеп матур...»

• Волонтер сүзе

# Казанны таныта алдык

**Динә САТТАРОВА**

Казан Универсиадасын мин түземсезлек белән көтеп алдым. Ярышлар вакытында миңа чирәмдәге хоккей үзәгендә VIP-кунакларыбызны: чит ил спортчыларын һәм оештыручыларны каршы алырга туры килде.

Әлбәттә, әлеге урынга эләгү өчен, мин зур сайлап алу конкурсы аша үттем. Инглиз телен белү дәрәҗәсенә, төрле ситуацияләрдән чыгу юлын таба белүгә аеруча басым ясалды. Чара башланыр алдыннан махсус әзерлек курслары үттек. Универсиадага кадәр дә чит ил спортчылары һәм оештыручылары белән эшләргә туры килгәнлектән, ул өлкәдә берникадәр тәҗрибәм булу сәбәпле, волотерлык иткәндә әллә ни кыенлыклар тумады. Бик күп яңа дуслар таптым, чит төбәкләрдән килгән яшьтәшләрем белән элемтә ныгыттым. Универсиада инглиз телен камилләштерү өчен дә менә дигән мөмкинлек тудырды.

Дөньяның төрле нокталарыннан килгән һәр спортчы безнең өчен үзенчәлекле иде. Гореф-гадәтләребезгә хөрмәт белән караулары аларга карата ихтирамны тагын да арттырды.

Дөньякүләм студент уеннарының нәкъ менә мәркәзебездә уздырылуы миндә зур горурлык хисе уятты. Без Казаныбызның тарихи байлыгын, гаҗәеп матурлыгын чит илдән килгән кунакларыбызга күрсәтә һәм таныта алдык.

# Матур булса да торган җир...

**Алинә САДЫЙКОВА,** хәбәрче

Кичке Казан бигрәк матур, аеруча хәзер: яшьләр, җәй, ял, каникул һәм күүүп туристлар. Төркем-төркем булып йөргән чит ил волонтерлары, спортчылары күп кешенең игътибарын җәлеп итә. Инглизчә бераз чамалагач, үзебезнең дә алар белән аралашу теләге туды.

### БЕЗГӘ МОНДА ОШЫЙ!

Беренче булып юлыбызга Сингапур делегациясенең спорт гимнастикасы төрен яратучылар очрады. Алар инде ярышларда катнашкан, үзләреннән таләп ителгәнне эшләгән. Һәм менә ял итү, күңел ачу, Казаныбыз белән танышу, аның матурлыгына соклану нияте белән, Бауман урамына килгәннәр. «Сез һәм волонтерлардан кала җирле халык белән аралашырга туры килмәде. Шулай да Казан халкы бик ачык йөзле һәм кунакчыл сыман тоела. Шәһәрегез дә искиткеч матур: җирле халык һәм кунаклар өчен күп мөмкинлекләр тудырылган. Безгә монда бик ошый!», – дип, Сингапур студентлары соклануларын яшерә алмады. Аларның Казанга һәм, гомумән, Россиягә беренче килүләре икән. «Универсиадага мондый мөмкинлек тудырганы өчен рәхмәтебезне әйтәбез. Сез искиткеч зур хезмәт куйгансыз. Россия җыелма командасы турында да берничә сүз әйтәсе килә: коллегаларыбыз бу бәйгегә бик җитди әзерләнгән. Без аларга карап сокланабыз!» – диделәр. Кунакларның эчкерсезлеге, гадилеге әңгәмәбезгә җылылык өстәде. Бу аралашудан соң, безнең ил кешеләренә мондый гадилек җитеп бетми икән, дигән фикер туды.

### АЛАР «РУБИН»НЫ БЕЛӘ!

Юлыбызда очраган Гонг-Конг политехник университетының беренче һәм өченче курс студентлары белән дә дуслашып өлгердек. Алар бадминтон, җиңел атлетика, 100 метрга йөгерү һәм озынлыкка сикерү буенча үз көчләрен сынаганнар. «Казанга килүебез беренче тапкыр, соңгысы да булмас! Монда бөтенесе дә идеаль, югары дәрәҗәдә! Без Универсиадада икенче тапкыр катнашабыз, шуңа күрә соңгы ярышлар белән чагыштыру мөмкинлеге бар. Казанда бу бәйгегә бик яхшылап, спортчы һәм гади халык мәнфәгатьләрен кайгыртып әзерләнгәнннәр. Моннан ике ел элек Шэньчжэньда узган Универсиадада транспорт мәсьәләсе уйланып бетмәгән иде. Анда спортчылар да, тамашачылар да бер транспортта йөрде. Кеше бик күп иде. Спорт объектларына барып җитү проблема тудырды, чөнки ярышлар буласы урыннарга бара белмәдек, аңлатмадылар да. Ә монда барысы да уйланылган һәм җиңел итеп эшләнгән», – дип, Кытай кунаклары Универсиада оештырылышын югары бәяләде. Шәһәр халкы өчен кайбер авырлыклар тудырылган булса да, нәтиҗәсе әйбәт, чит ил вәкилләре дә канәгать! Казанга беренче тапкыр гына килсәләр дә, Гонг-Конглылар шәһәребез белән инде таныш булганнар. Китаплардан укып, телевизион тапшырулардан карап беләләр микән дип уйлыйсызмы? Ялгышасыз, Казаныбызны «Рубин» футбол командасы таныткан икән!

### ОЗЫН СҮЗНЕҢ КЫСКАСЫ...

Кытай студентлары белән истәлек фотолары ясаганнан соң, Бауман буенча сәяхәтебезне дәвам иттек. Күп тә үтми, игътибарыбызны озын буйлы егетләр җәлеп итте. Алар Американың Калифорния штатыннан булып чыктылар (*уңдагы фото*). «Без су полосы белән шөгыльләнәбез һәм менә Универсиадада да катнашырга булдык. Әлегә барысы да уңышлы бара, ярышлар дәвам итә. Казан безне бик җылы каршы алды: җирле халык дустанә, шәһәр архитектурасы искиткеч матур, күп кешеләр белән аралаштык, яңа дуслар таптык», – ди егетләр. Калифорния кунакларының Универсиададада катнашулары һәм Россиягә беренче визитлары икән: «Без Россия башкача кабул итәр дип уйлаган идек, әмма... кешеләре бик сөйкемле», – дип сүзне борды егетләр. Ни өмет иткәннәре турында кат-кат сорасак та, алар безгә елмаю белән генә җавап бирде.



### ИНГЛИЗЧӘ ДӘ ЯХШЫ БЕЛ!

Чит ил спортсменнары белән шулай җиңел танышып, аралашып булуына чын күңелдән сөендек. Бүгенгә җитәр дип уйлаган гына идек, Таиландтан коллегаларыбыз (*сулдагы фото*) – телевидение һәм газета хезмәткәрләренә юлыктык: бик аралашучан һәм ачык йөзле халык икән. «Казан бик борынгы һәм бөек шәһәр икән. Монда бөтен нәрсә төрле, бездәге шикелле түгел: кешеләр, мәдәният, ашамлыклар, менталитет үзгә. Мондый контрастлыкны күзәтү үзенә күрә бер кызык», – дип, фикерләре белән уртаклашты кунаклар. Алган тәэсирләре яхшы иде кебек. Спортчыларга тәрҗемәчеләр беркетелгән булса, медиа хезмәткәрләренә әллә волонтерлар калмаган, ахры, әллә безгә генә шундыйлар очрады. Алар да тизрәк проблемалары белән уртаклашырга ашыкты: «Безнең өчен иң зур проблема телне белмәү булды. Ашап аласы килгән вакытта, ашханәләр таба алмый интектек. Инглиз телен бөтен кеше дә белеп бетерми. Күпчелек урыннарда русча язылган. Ә тулаем алганда, без бик канәгать!»




Аралашудан без дә бик канәгать калдык һәм мондый мөмкинлек булдырылган өчен Универсиадага рәхмәт. Әле кайчан чит ил спортчылары белән танышып, рәхәтләнеп үз кешеләр кебек аралаша алыр идек? Матур булса да торган җир, сагындыра туган ил, диләрме әле? Чит ил кунаклары үзләренә кайткач, безнең турыда бары тик матур итеп кенә искә алсыннар иде.

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 500
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълумати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.